«РАСЛЫЙМ»
Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Татар телен саклау һәм үстерү мәсьәләләре комиссиясе рәисе
_____________________М.Г. Әхмәтов

**Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Татар телен саклау һәм үстерү мәсьәләләре комиссиясе утырышы беркетмәсе**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы,
2022 елның 22 марты

Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Татар телен саклау һәм үстерү мәсьәләләре комиссиясе утырышын Комиссия рәисе М.Г. Әхмәтов алып бара.

**Катнаштылар:** исемлек буенча.

Көн тәртибе буенча каралды:

**1. Татарстан Республикасында милли сәясәтне тормышка ашыру**

– Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Татар телен саклау һәм үстерү мәсьәләләре комиссиясе эшчәнлеге турында мәгълүмат;
– Татарстан Республикасында милли мәгариф торышы;
– Татарстан Республикасында мәдәният өлкәсендә милли сәясәт;
– Яшьләргә милли тәрбия бирүдә дәвамчанлыкны тәэмин итү;
– Милли үзаң тәрбияләүдә массакүләм мәгълүмат чаралары;
– Милли сәясәтне тормышка ашыруда Казан шәһәре тәҗрибәсеннән.

Чыгыш ясадылар: М.Г. Әхмәтов, И.Г. Һадиуллин, И.Х. Әюпова, Т.Җ. Сөләйманов, А.С. Сәлимгәрәев, Г.Р. Сәгыйтова.

Түбәндәге **карарлар кабул ителде:**

1. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына, Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгына, «Татмедиа» Республика матбугат һәм массакүләм

коммуникацияләр агентлыгына, Казан шәһәре Башкарма комитетына үз эшчәнлекләре кысаларында милли сәясәтне гамәлгә ашыру, туган телләрне саклау һәм үстерү мәсьәләсенә игътибарны арттырырга, әлеге юнәлештәге эшне дәвам итәргә.

2. Татарстан Республикасында милли мәгарифне саклау һәм үстерү максатыннан, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

– яңартылган федераль дәүләт белем бирү стандартларын кертү шартларында туган телдә белем бирү, туган телләрне өйрәнү өчен шартлар тудырырга, укыту-тәрбия процессын республикада яшәүче халыкларның этномәдәни мирасын, күпмәдәни үзенчәлекләрне һәм полилингваль компонентны нәтиҗәле файдалану нигезендә оештыру эшен дәвам итәргә;

– Татарстан Республикасы муниципаль район һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнары белән берлектә билингваль белем бирү мохите шартларында туган телләрне укытуның нәтиҗәле модельләрен билгеләү буенча база белем бирү оешмалары эшчәнлеген тәэмин итәргә;

– милли мәгариф системасы өчен педагогик кадрлар әзерләүне һәм өзлексез белем күтәрүне яңарту һәм камилләштерү эшен дәвам итәргә;

– «Татарстан Республикасы мәгарифне үстерү институты» өстәмә һөнәри белем бирү дәүләт бюджет учреждениесе, «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе» дәүләт фәнни бюджет учреждениесе белән берлектә дәреслекләр әзерләү, аларга апробация үткәрү, кулланышка кертү, туган тел һәм әдәбият укытучыларына методик ярдәм күрсәтү эшен дәвам итәргә;

– Татарстан Республикасы муниципаль район һәм шәһәр округларының туган телдә белем бирүче уку йортларының укыту-методик, материаль-техник базасын ныгыту эшен дәвам итәргә;

– Татарстан Республикасы муниципаль район һәм шәһәр округларының милли һәм территориаль үзенчәлекләрен исәпкә алып, туган телдә гомуми белем бирү оешмалары эшчәнлеген методик яктан тәэмин итүне гамәлгә ашырырга;

– туган телләрендә олимпиадалар һәм башка интеллектуаль, иҗади конкурслар уздыру юлы белән сәләтле балаларны ачыклау һәм үстерү өчен шартлар тудыру эшен дәвам итәргә;

– Татарстан Республикасының муниципаль район һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнары белән берлектә, Татарстан халыкларының төбәк милли-мәдәни автономияләрен җәлеп итеп, муниципаль

район һәм шәһәр округларындагы туган телдә белем бирүче оешмаларның Россия Федерациясе субъектларында урнашкан этномәдәни компонентлы мәктәпләр белән хезмәттәшлеген активлаштырырга.

3. Татарстан Республикасының муниципаль район һәм шәһәр округлары башлыкларына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

– Татарстан Республикасының муниципаль районнары һәм шәһәр округларының мәктәпкәчә һәм гомуми белем бирү оешмаларында һәм өстәмә белем бирү кысаларында тулы тел мохите булдырырга, муниципаль берәмлек җирлегендә яшәүче халыкларның туган телләрен, мәдәниятләрен һәм гореф-гадәтләрен өйрәнү өчен шартлар тудырырга;

– Татарстан Республикасының муниципаль район һәм шәһәр округларында яшәүче халыкларның телләрен, мәдәниятләрен һәм традицияләрен өйрәнү буенча якшәмбе мәктәпләре бүлекләренең эшен оештырырга, аларның эшчәнлеген популярлаштыру буенча даими эш алып барырга;

– массакүләм мәгълүмат чараларында, муниципаль район һәм шәһәр округларының рәсми аккаунтларында, мәгариф оешмаларының рәсми сайтларында, социаль челтәрләрдә туган телләрдәге чараларны киң яктыртуны тәэмин итәргә;

–белем алучыларның этник үзаңын формалаштыруга, үз халкының тарихы, теле, үз туган ягының мәдәнияте, Россия һәм кешелек халыкларының мәдәни мирасы нигезләре турында белем бирүгә юнәлдерелгән тәрбия эшен оештырырга;

– балаларда туган телгә һәм милли кыйммәтләргә, традицияләргә мәхәббәт тәрбияләүдә гаиләнең ролен популярлаштыру эшен активлаштырырга;

– туган халкының һәм башка милләтләрнең мәдәниятен танып белү, аларга карата хөрмәт тәрбияләү ысулы буларак, балаларда китап уку белән кызыксынуны үстерү буенча эш оештырырга.

Беркетмәне
Комиссия секретаре
Ч.Ш. Гарипова
алып барды